| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «УРМЫШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «УРМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 1 августы №30

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Объектларның техник торышын бәяләү һәм объектларның ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын техник регламентлар таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре нигезендә биналарны, корылмаларны карауны уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 1 мартындагы 3 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге советына таянып, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Урмышлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы карар бирде:

1. «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Объектларның техник торышын бәяләү һәм объектларның ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын техник регламентлар таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре нигезендә биналарны, корылмаларны карауны уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының 2023 елның 1 мартындагы 3 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2.Әлеге карарны Урмышлы авылы, Үзәк урамы, 4 нче йорт, Яңа Елховой авылы, Родничная урамы, 22 нче йорт, Бохар авылы, Авангард урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
Лениногорск муниципаль
«Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы, Совет рәисе А.Ф.Хәбибуллин